**Татарстан Республикасы**
**Лениногорск муниципаль районы**
**Писмән авыл җирлеге**
**Дала Зәе авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2021 елның 21 ноябре № 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлегенең Дала Зәе авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Писмән авыл җирлеге Дала Зәе авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлеге Дала Зәе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән,1 һәм 2 теркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 300 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Дала Зәе авылында юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту) ;
- Дала Зәе авылы территориясен төзекләндерүне оештыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Писмән авылы, Гагарин урамы, 5 йорт, Восходавылы Үзәк урам 50 йорт – авыл мәдәният йорты , 1нче адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.В.Насретдинов